**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«30» декабрь 2022 ел № 5002

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлегенә үзгәрешләр кертү тәртибен һәм срокларын раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 160.1 статьясы һәм «Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте органнарына (дәүләт органнарына), территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары белән идарә итү органнарына, җирле үзидарә органнарына, җирле администрация органнарына бюджет керемнәренең баш администраторы вәкаләтләрен беркетүгә һәм Россия Федерациясе субъекты бюджеты, территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты, җирле бюджет керемнәренең баш администраторлары исемлеген раслауга карата гомуми таләпләрне раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 16 сентябрендәге 1569 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлегенә үзгәрешләр кертү тәртибен һәм срокларын расларга.
2. «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлегенә үзгәрешләр кертү тәртибен һәм срокларын раслау турында» Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 15 мартындагы 733 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.
4. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (tukay.tatarstan.ru), шулай ук Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http//pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

Башкарма комитет Җитәкчесе А.Р. Хәбибуллин

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның «30» 12 5002 номерлы карары белән расланды

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлегенә үзгәрешләр кертү тәртибе һәм сроклары

1. Әлеге тәртип «Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте органнарына (дәүләт органнарына), территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары белән идарә итү органнарына, җирле үзидарә органнарына, җирле администрация органнарына бюджет керемнәренең баш администраторы вәкаләтләрен беркетүгә һәм Россия Федерациясе субъекты бюджеты, территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты, җирле бюджет керемнәренең баш администраторлары исемлеген раслауга карата гомуми таләпләрне раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 16 сентябрендәге 1569 номерлы карары карары нигезендә эшләнгән һәм Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы бюджетының баш администраторлары исемлегенә үзгәрешләр кертү тәртибен һәм срокларын билгели (алга таба – исемлек, баш администратор).

2. Исемлеккә түбәндәге очракларда үзгәрешләр кертелергә мөмкин:

- Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы бюджеты керемнәренең баш администраторлары составы һәм (яки) вәкаләтләре үзгәрү;

- Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы бюджет керемнәре классификациясе коды (керем төре (ярдәмче төр) коды) һәм (яки) исеме үзгәрү.

3. Исемлеккә үзгәрешләр кертү Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы рәисе боерыгы белән гамәлгә ашырыла, ул керемнәрнең баш администраторлары тәкъдимнәре нигезендә исемлекне раслаучы Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертмичә башкарыла.

4. Керемнәрнең баш администраторлары, исемлеккә үзгәрешләр кертергә кирәк булган очракта, алар барлыкка килгән көннән алып 5 көннән дә соңга калмыйча, Тукай муниципаль районы Финанс-бюджет палатасына тиешле тәкъдимнәрне түбәндәге мәгълүматны күрсәтеп бирәләр:

- исемлеккә үзгәрешләр кертү өчен нигезләр;

- керемнәрнең баш администраторы коды һәм исеме;

- керемнәр төре (ярдәмче төре) коды һәм исеме.

5. Тукай муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы:

- мәгълүмат керү датасыннан соң килгән 3 эш көне дәвамында аны әлеге Тәртипнең 2 һәм 4 пунктларында билгеләнгән таләпләргә туры килүгә карый;

- кимчелекләр булмаган очракта, мәгълүмат кергән көннән соң килүче 5 эш көненнән дә соңга калмыйча, исемлеккә үзгәрешләр кертә;

- кисәтүләр булган очракта, керемнәрнең баш администраторына исемлеккә үзгәрешләр кертүдән баш тарту турында язма рәвештә хәбәр итә.